Проект

**Төп гомуми белем бирү программалары буенча төп дәүләт имтиханы (ТДИ) рәвешендә дәүләт йомгаклау аттестациясе**

**ТАРИХ буенча 2016 елда төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен контроль үлчәү материалларының күрсәтмә (демонстрацион) варианты**

«ПЕДАГОГИК ҮЛЧӘНЕШЛӘР ФЕДЕРАЛЬ ИНСТИТУТЫ»
Федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениеесе тарафыннан әзерләнде



**ТАРИХ буенча 2016 елда төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен контроль үлчәү материалларының күрсәтмә (демонстрацион) варианты**

**Имтихан эшенең демонстрация вариантына аңлатма**

2016 ел демонстрация варианты белән танышканда шуны күз алдында тотарга кирәк: демонстрация вариантына кертелгән биремнәр 2016 елда контроль үлчәү материаллары (алга таба – КҮМ) вариантлары ярдәмендә тикшерелүче барлык эчтәлек вариантларын чагылдырмый. 2016 ел имтиханында тикшерелергә мөмкин булган эчтәлек элементларының тулы исемлеге www.fipi.ru сайтында урнаштырылган Төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен укучыларның әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр һәм эчтәлек элементлары кодификаторында китерелә. Кодификаторда гомуми тарих буенча белемнәрне җәлеп итеп тикшерелүче эчтәлек элементлары аерып (*) күрсәтелә.

Демонстрация варианты имтиханда катнашучы һәркемгә һәм киң җәмәгатьчелеккә булачак имтихан эшенең структурасы, биремнәр саны һәм рәвеше, шулай ук аларның катлаулылык дәрәҗәсе турында күзаллау булдыру мөмкинлеге бирүгә юнәлтелгән. Бу вариантка кертелгән киңәйтелгән җаваплы биремнәрне үтәүне

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

бәяләүнең монда китерелгән критерийлары киңәйтелгән җавапны язуның тулылыгына һәм дөреслегенә таләпләр турында күзаллау тудырырга мөмкинлек бирә.

Бу мәгълүмат чыгарылыш укучыларына тарих буенча имтихан тапшыруга әзерлекнең стратегиясен эшләү мөмкинлеге тудыра.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



## 2016 ел демонстрация варианты
## Эшне үтәү буенча күрсәтмә

Имтихан эше 35 биремне үз эченә алган ике өлештән тора. 1 өлеш кыска җаваплы 30 биремнән, 2 өлеш киңәйтелгән җаваплы 5 биремнән гыйбарәт.

Тарих буенча имтихан эшен үтәүгә 3 сәгать (180 минут) вакыт бирелә.

1-22 биремнәргә җаваплар бер сан белән языла, ул дөрес җавап санына туры килә. Бу санны эш текстындагы җавап кырына язып куегыз.

23-30 биремнәргә җаваплар сүз (сүзтезмә), сан яки саннар эзлеклелеге рәвешендә эш текстындагы җавап кырында язып куела.

1 өлеш бирәменә дөрес булмаган җавап язган очракта, аны сызыгыз һәм янәшәсендә яңа җавап язып куегыз.

31-35 биремнәргә киңәйтелгән җавап бирергә кирәк. 31 һәм 32 биремнәр тарихи чыганакка анализ ясауны күздә тота. 33-35 биремнәр бирелгән темаларга киңәйтелгән җаваплар сорый. 31-35 биремнәр аерым биттә үтәлә.

Биремнәрне үтәгәндә караламадан файдаланырга мөмкин. Караламадагы язмалар эшне бәяләгәндә исәпкә алынмый.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Сезнең тарафтан биремне үтәгәндә алынган баллар бергә кушыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремне үтәргә һәм иң зур сандагы балларны җыярга тырышыгыз.

***Уңышлар телибез!***

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



## 1 өлеш

**1-22 биремнәрне үтәгәндә җавап кырында дөрес җавапка туры килүче бер сан языгыз**

**1** Үзәге Киевта булган Борынгы Рус дәүләте кайсы гасырга карый?

1) VIII гасыр 2) IX гасыр 3) X гасыр 4)XI гасыр

Җавап: ☐

**2** Борынгы Рус дәүләтендә Русская Правда – ул

1) Борынгы Рус дәүләтенең законнар җыелмасы
2) беренче Борынгы рус елъязмасы
3) Русь һәм Византия арасындагы шартнамә атамасы
4) Киев кенәзе тарафыннан язылган әдәби әсәр

Җавап: ☐

**3** Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы XVII гасыр башындагы Фетнәнең нәтиҗәсе булып тора:

1) рус җирләрен Мәскәү тирәсенә берләштерү процессының тәмамлануы
2) Украина җирләренең Россия составына керүе
3) Мәскәү кенәзләре – Иван Калита династиясен туктату
4) Россия тәхенә Романовлар династиясе килү

Җавап: ☐

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

**4** Тарихчы язмасыннан өзек укыгыз һәм өземтәдә искә алынган патшаны атагыз.

«Опричнина дәүләт сатлыкҗанлыгы эшләре буенча иң югары полиция билгеләнүен алды. Опричнинага язылган мең кешелек, аннан соң 6 мең кешегә җиткән отряд эчке крамола дозорчылары корпусына әверелде. Малюта Скуратов, ягъни Григорий Яковлевич Плещеев-Бельский, митрополит Алексийның кардәше, бу корпусның шефы кебек булды, ә патша үзенә руханилардан, боярлардан һәм барлык җирдән бу крамолага каршы көрәш өчен полиция диктатурасын сорап алды”.

1) Иван III
2) Иван IV
3) Фёдор Иванович
4) Борис Годунов

Җавап: ☐

**5** Түбәндә санап кителгән 1905-1907 еллар инкыйлабы вакыйгаларының кайсысы башкалардан соңрак булды:

1) 17 октябрь манифестын кабул итү
2) Канлы якшәмбе
3) II Дәүләт Думасын тарату
4) «Кенәз Потемкин-Таврический» броненосецында восстание

Җавап: ☐

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



**6** Император канцеляриясенең III бүлекчәсе түбәндәге максатларда оештырылды:

1) бердәм законнар җыелмасы булдыру
2) крепостнойлык хокукын бетерү өчен проектлар эшләү
3) җәмгыятькә полиция контролен көчәйтү
4) дәүләт крестьяннарының хәлен яхшырту

Җавап: ☐

**7** Екатерина II хакимлек иткән елларда Кара диңгезгә чыгу мөмкинлеге түбәндәге сәбәпләр буенча кирәк булды

1) рус-төрек сугышлары
2) Польша белән Мәңгелек тынычлык урнаштыру
3) Россиянең Польшаны бүлүдә катнашуы
4) Россия империясенең Франциягә каршы сәясәте

Җавап: ☐

**8** Рус полководецының императорга язган рапортыннан өзекне укыгыз һәм авторын атагыз.

«Галиҗанәп государь, дошманның Мәскәүгә керүе ул әле Россияне буйсындыру түгел икәнлеген сезгә җиткерергә батырчылык итәм. Киресенчә, мин коткарырга өлгергән гаскәрләр белән Тула юлында хәрәкәт итәм. Бу мине Тула шәһәрен <...> һәм Брянскины <...> якларлык хәлгә китерә һәм безнең губернияләрдә күпләп әзерләнгән ресурсларны капларга мөмкинлек бирә».

1) А.В. Суворов
2) М.И. Кутузов

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

3) П.И. Багратион
4) М.Д. Скобелев

Җавап: ☐

**9** Ул идарә иткән чорда Русь тулысынча Алтын Урда хакимлегеннән котылган Мәскәү кенәзен атагыз
1) Иван Калита
2) Дмитрий Донской
3) Иван III
4) Василий III

Җавап: ☐

**10** Авторы Владимир Мономах булган борынгы рус әдәби әсәрен күрсәтегез
1) «Закон һәм иркенлек турында» («Слово о законе и благодати»)
2) «Замана еллары повесте» («Повесть временных лет»)
3) «Балаларга сабак» («Поучение детям»)
4) «Борис һәм Глеб тормышы» («Житие Бориса и Глеба»)

Җавап: ☐

**11** СССР икътисадын үстерүнең икенче бишъеллык планы түбәндәге елларда тормышка ашырылды:
1) 1920 елларда
2) 1930 елларда
3) 1940 елларда

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



4) 1950 елларда

Җавап: ☐

**12** Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы Россиядә Гражданнар сугышына карый?
1) Брусилов һөҗүме
2) Порт-Артур оборонасы
3) генерал П.Н. Врангель гаскәрләрен тар-мар итү
4) Брест крепостен саклау

Җавап: ☐

**13** Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы нэп нәтиҗәләренең берсе булып тора?
1) Шәһәр халкының саны авыл халкына караганда артып китүе
2) Кулакларның бетерелүе
3) Илебезнең тизләтелгән рәвештә индустриальләшүе
4) Сәнәгать җитештерүе күләме буенча илебез 1913 елгы күрсәткечләргә иреште

Җавап: ☐

**14** Фашистлар Германиясенең СССРга һөҗүме шартлы рәвештә ничек аталды?
1) «Тайфун»
2) «Цитадель»
3) «Барбаросса»
4) «Ост»

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Җавап: ☐

**15** Бөек Ватан сугышы хәрби операцияләренең берсе турындагы текстны укыгыз. Әлеге хәрби операция нәтиҗәсендә кайсы совет республикасы азат ителә?

«Операция планы дошман оборонасын бер үк вакытта алты урында өзүне күздә тотты. «Багратион» операциясен уңышлы үтәү Мәскәү юнәлешен дошман гаскәрләреннән тулысынча чистартырга, барлык территорияне азат итүне тәгәлләргә... Балтыйк диңгезе яр буена һәм Көнчыгыш Пруссия чикләренә чыгарга мөмкинлек бирә иде».

1) Украина
2) Белоруссия
3) Молдовия
4) Эстония

Җавап: ☐

**16** Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1950 елларда булды?

1) Н.С. Хрущевның отставкага китүе
2) СССР Конституциясен кабул итү
3) СССР Халык депутатларының I съезды
4) КПССның XX съезды

Җавап: ☐

**17** «Прага язы» нәрсә белән тәгәлләнде?

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



1) Чехословакия коммунистлар партиясенең реформистлык агымы җиңелүе
2) Чехословакиядә коммунистларга оппозициядә булган сәяси көчләрнең хакимияткә килүе
3) Варшава шартнамәсе оешмасы таркалу
4) Чехословакиянең Чехия һәм Словакиягә таркалуы

Җавап: ☐

**18** Е.Т. Гайдар истәлекләреннән өзекне укыгыз һәм бәян ителгән вакыйгалар булган елны күрсәтегез.

«2 гыйнвардан зур күпчелек товарларга (икмәк, сөт, спиртлы эчемлекләр, шулай ук коммуналь хезмәтләр, транспорт һәм энергия чыганакларыннан тыш) бәяләр иректе куелды, ә җайга салынучыларга – күтәрелде...

Либеральләштерү алдыннан ясаган чыгышларымда мин башлангыч бәяләрне 200-300 процентка күтәрү турында сөйләдем. Ә чынлыкта исә гыйнварда аларның үсеше алдагы ай белән чагыштырганда 352 процент тәшкил итте».

1) 1962 ел
2) 1985 ел
3) 1992 ел
4) 1998 ел

Җавап: ☐

**19** РФнең беренче Президенты кем?

1) В.В. Путин
2) Б.Н. Ельцин

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

3) М.С. Горбачёв
4) Е.Т. Гайдар

Җавап: ☐

**20** Схеманы карагыз һәм биремне үтәгез.




© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



Схемада күрсәтелгән маршрут буенча беренче тапкыр узган экспедицияне җитәкләгән сәяхәтче исемен күрсәтегез.
1) Е.П. Хабаров
2) И.Ф. Крузенштерн
3) В.Д. Поярков
4) С.И. Дежнёв


Җавап: ☐

**21** 1920-1930 еллар монументаль сәнгать һәйкәле булып тора
1) В.И. Мухинаның «Эшче һәм колхозчы» скульптурасы
2) И. Мартосның Минин һәм Пожарскийга һәйкәле
3) М. Микешинның «Россиянең меңъеллыгы» һәйкәле
4) Е.В. Вучетичның «Ватан-ана чакыра!» скульптурасы

Җавап: ☐

**22** Рәсемне карагыз һәм биремне үтәгез.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте




Әлеге карикатура багышланган вакыйга булган чорны күрсәтегез.
1) 1920 елларның икенче яртысы
2) 1930 елларның беренче яртысы
3) 1930 елларның икенче яртысы
4) 1940 елларның беренче яртысы

Җавап: [ ]

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



**23-30 биремнәр эш текстының җавап кырында языларга тиешле саннар, саннар эзлеклелеге яисә сүз (сүзтезмә) рәвешендә җавап бирүне таләп итә. Россия патшаларының исемнәре бары тик хәрефләр белән языла (мәсәлән, Николай Икенче).**

**23** Тарихи вакыйгаларны хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Тарихи вакыйгалар билгеләнгән саннарны таблицага дөрес тәртиптә языгыз.
1) Россиядә крепостнойлык хокукын бетерү
2) Юрьев көненнән бер атна алдан һәм бер атна соң крестьян күчешен чикләү
3) патша Алексей Михайловичның Законнар җыелмасын кабул итү
4) беренче Земство соборын чакыру

Җавап:

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |

**24** 1864 елгы суд реформасының нигезләмәләре һәм әлеге нигезләмәләрдә билгеләнгән принциплар арасында тәңгәллек табыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

| СУД РЕФОРМАСЫ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ | ПРИНЦИПЛАР |
|---|---|
| А) Хөкем урыннары халык утырышларында башкарылучы эшләр турында гомуми мәгълүмат | 1) судның бәйсезлеге<br>2) судның барлык катлауларга каравы<br>3) судның |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | |
|---|---|
| өчен матбугатта басарга рөхсәт ителә.<br>Б) Суд хакимияте... һәркемгә һәм барлык граждан эшләренә дә, җинаять эшләренә дә кагыла.<br>В) Суд эшчәнлегендә яклау һәм гаепләү вәкилләре катнаша. | хәбәрдарлыгы<br>4) процессның бәхәсләшү юлы белән алып барылуы |

Таблицага тиешле хәрефләр астына сайлап алынган саннарны языгыз.

Җавап:

| А | Б | В |
|---|---|---|
| | | |

**25** 1917 елның апрелендә большевиклар нинди лозунглар күтәреп чыкты? Түбәндә китерелгән исемлектән ике лозунг табыгыз һәм таблицага алар күрсәтелгән санны языгыз.

1) «Бөтен хакимият Советларга!»
2) «Самодержавиене бетерергә!»
3) «Җиңгәнче сугышырга!»
4) «Вакытлы хөкүмәткә бернинди ярдәм юк!»
5) «Барыбыз да Деникинга каршы көрәшкә!»

Җавап:

| | |
|---|---|
| | |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



**26** Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*Төрле илләрдән Россия икътисадына инвестицияләр керү*

| Ел | Франция | Англия | Германия |
|---|---|---|---|
| 1880 | 31,4 млн сум | 30,1 млн сум | 29,8 млн сум |
| 1890 | 66,6 млн сум | 35,3 млн сум | 79,0 млн сум |

| ФИКЕРНЕҢ БАШЫ | ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ВАРИАНТЛАРЫ |
|---|---|
| А) 1890 елга Россия икътисадында ...өстенлекле булып тора<br>Б) XIX гасыр ахырына Россия икътисадына чит ил инвестицияләре...<br>В) XIX гасыр ахырында иң аз үсештә .... булып тора | 1) арттылар<br>2) Германия инвестицияләре<br>3) Англия инвестицияләре<br>4) Франция инвестицияләре<br>5) кимеделәр |

Таблицага тиешле хәрефләр астына сайлап алынган саннарны языгыз.

Җавап:

| А | Б | В |
|---|---|---|
| | | |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

**27** Нинди термин турында сүз бара, аны язып куегыз.
СССРда «җепшеклек» чорында нинди дә булса җинаять эшләүдә нигезсез гаепләнгән һәм гепсезгә хөкем ителгән кешенең югалткан намуслы исемен һәм хокукын торгызуны белдерүче термин аеруча киң таралу алды.

Җавап: ___________________________________.

**28** Россия дәүләтенең XVI гасырда һәм XVIII гасырның икенче яртысында икътисадый үсеше үзенчәлекләрен чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларны, икенчесенә – аермалыкларны сайлап алып языгыз.
1) эчке таможня пошлиналарының булуы
2) мануфактура производстволары эшләве
3) йөкләрне тимер юл транспортында күчерүнең мөмкин булмавы
4) авыл хуҗалыгының әһәмияте өстен булу


Җавап:

| Охшашлыклар | | Аермалыклар | |
|---|---|---|---|
| | | | |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



**29** Схемада төшеп калган фамилияне языгыз.




Җавап: ___________________________________.

**30** Түбәндә терминнар исемлеге бирелгән. Берсеннән кала, аларның барысы да сословиеләрне аңлата.
*1) дворянлык; 2) мещанлык; 3) крестьяннар; 4) түрәләр;5)руханилар*
Әлеге рәттән «төшереп калдырылырга» тиешле терминның тәртип номерын табыгыз һәм языгыз.

Җавап: ☐

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

## 2 өлеш

**Әлеге өлештәге биремнәргә (31-35) җавап бирү өчен аерым кәгазь битеннән файдаланыгыз. Башта бирем номерын (31, 32 һ.б.), аннары аңа җавапны языгыз. Җавапларны төгәл һәм аңлашылырлык итеп языгыз.**

**Тарихи чыганактан өзекне укыгыз һәм 31, 32 биремнәрне үтәгез. Җавапларда текст мәгълүматыннан, шулай ук тарих курсыннан белгәннәрегезне файдаланыгыз.**

*КПСС Үзәк Комитеты Генераль секретаре докладыннан өзек:*

«Мәгълүм ки, соңгы елларда уңайсыз тенденцияләр көчәйде, байтак кыенлыклар килеп чыкты. Партиянең актив эшләве белән 1983 елдан алып, халык хуҗалыгының күп кенә буыннары эшен күтәрергә һәм хәлне беркадәр яхшыртырга мөмкин булды. Ләкин <...> авырлыклар һич тә бетерелмәде, безгә алга таба тиз хәрәкәт итү өчен ышанычлы нигез булдыруда шактый көч куясы бар әле...

Әлбәттә, табигать һәм байтак кына тышкы факторлар йогынтысы булды. Ләкин иң мөһиме җитештерүне үстерүнең объектив шартларындагы

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



үзгәрешләр үз вакытында тиешенчә бәяләнмәвендә, аны интенсивлаштыруны тизләтүдә, хуҗалык итү ысулларындагы үзгәрешләр зарурлыгы, дип уйлыйм һәм, бу бигрәк тә мөһим, икътисад өлкәсендә зур чаралар эшләүдә һәм аларны тормышка ашыруда тырышлык куелмады. Иптәшләр, безгә килеп туган вәзгыятьне тирәнтен һәм ахыргача аңларга һәм иң җитди нәтиҗәләр ясарга кирәк. Илнең тарихи язмышы, социализмның хәзерге дөньяда тоткан урыны күпчелек очракта безнең эшне киләчәктә ничек алып баруыбызга бәйле <...>

Төп мәсьәлә илебезнең икътисадый үсешкә ничек һәм нәрсә исәбенә ирешә алуына кайтып кала.. <...>»

**31** Доклад авторын һәм әлеге сәяси эшлекле ил белән җитәкчелек иткән чорны күрсәтегез.

**32** Өзекнең беренче абзацыннан сәбәпләре икенче абзацта күрсәтелгән вазгыять тасвирланган җөмләне табыгыз һәм языгыз. Әлеге хәлнең ким дигәндә ике сәбәбен күчереп языгыз.

**33-35 биремнәр эшчәнлекнең төрле рәвешләрен күз алдында тота: тарихи вакыйгага анализ бирү (33), тарихи вакыйгаларны һәм күренешләрне чагыштыру (34), бирелгән темага җавап планын төзү (35). Әлеге биремнәрне үтәгәндә һәрбер сорауның**

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

**формулировкасына игътибар итегез.**

**33** Язгы чәчү алдыннан крестьяннар, җирле һәм үзәк хакимиятнең көчсезләнүеннән файдаланып, җирле алпавытларның җирләрен һәм мөлкәтен бүлә башлады. Ә көзен крестьяннарга алпавыт җирләрен законлы рәвештә бүлә алу хокукы теркәлгән Советлар съезды декреты бастырып чыгарылды.

1. Әлеге вакыйгалар булырга мөмкин булган елны күрсәтегез.
2. Ни өчен җирле һәм үзәк хакимият көчсезләнде һәм аннан крестьяннар файдалана алды?
3. Аның нигезендә алпавыт җирләрен бүлү законлаштырылган документ ничек атала?

**34** Шундый фикер яшәп килә: таркалганлык чорында, сәяси мөстәкыйль кенәзлекләр корылышында аерымлыклар булуга да карамастан, рус җирләре үсешендә бик күп охшашлыклар булды. Әлеге охшашлыкларны раслаучы кимендә ике факт китерегез.

**35** Сезгә “Бөек Ватан сугышы барышында тамырдан

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



борылыш” темасы буенча киңәйтелгән җавап әзерләргә кушылган. Сезгә әлеге теманы яктырту өчен нигез булып торачак план төзегез.

План кимендә өч пункттан торырга тиеш. Теләсә-кайсы ике пунктның кыскача эчтәлеген языгыз.

Аңлатмалы план Бөек Ватан сугышы барышында тамырдан үзгәрешләр белән бәйле төп вакыйгаларны (күренешләрне) чагылдырырга тиеш.

*Әлеге теманы тулысынча ачарга ярдәм итүче план төзергә кыенсынсагыз, теманың бер мөһим соравын (кисәк, юнәлеш, мәсьәлә) сайлап алырга мөмкин.*
*Үзегез сайлап алган сорау буенча планның исемен языгыз (кисәк, юнәлеш, мәсьәлә) һәм аның эчтәлеген ачып бирүче план төзегез. План төзегәндә пунктлар һәм аңлатмалар санына таләпләрне үтәгез.*

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

## Тарих буенча имтихан эшен бәяләү системасы

### 1 өлеш

1 өлештәге биремнәргә һәр дөрес җавап өчен, 24 һәм 26 биремнәрдән кала, 1 балл бирелә. 1-30 биремнәр, таләп ителгән бер-ике сүз, сан яисә саннар эзлеклелеге дөрес күрсәтелгән очракта, дөрес үтәлгән дип санала.

24 һәм 26 биремнәр түбәндәге принцип буенча бәяләнә: 2 балл – хаталар булмаса; 1 балл – бер хата булса; 0 балл – ике яисә аннан да күбрәк хата булганда.

| Бирем номеры | Җавап |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 2 | 1 |
| 3 | 4 |
| 5 | 3 |
| 6 | 3 |
| 7 | 1 |
| 8 | 2 |
| 9 | 3 |
| 10 | 3 |
| 11 | 2 |
| 12 | 3 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



| | |
|---|---|
| 13 | 4 |
| 14 | 3 |
| 15 | 2 |
| 16 | 4 |
| 17 | 1 |
| 18 | 3 |
| 19 | 2 |
| 20 | 4 |
| 21 | 1 |
| 22 | 3 |
| 23 | 2431 |
| 24 | 324 |
| 25 | 14 |
| 26 | 213 |
| 27 | Реабилитацияләү |
| 28 | 3412 |
| 29 | Пестель |
| 30 | 4 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

## 2 өлеш

## Киңәйтелгән җаваплы биремнәрне бәяләү критерийлары

2 өлештәге биремнәр җавапның тулылыгыннан һәм дөреслегеннән чыгып бәяләнә. 31 һәм 32 биремнәрдәге тарихи чыганакка анализ һәм 34 биремдәге тарихи вакыйгаларны чагыштыру өчен 0 баллдан алып 2 балл куела. 33 биремдәге тарихи вакыйганы анализлау һәм 35 биремдәге бирелгән темага җавап планын төзү өчен 0 баллдан алып 3 баллга кадәр куелырга мөмкин.

*КПСС Үзәк Комитеты Генераль секретаре докладыннан өзек:*

«Мәгълүм ки, соңгы елларда уңайсыз тенденцияләр көчәйде, байтак кыенлыклар килеп чыкты. Партиянең актив эшләве белән 1983 елдан алып, халык хуҗалыгының күп кенә буыннары эшен күтәрергә һәм хәлне беркадәр яхшыртырга мөмкин булды. Ләкин <...> авырлыклар һич тә бетерелмәде, безгә алга таба тиз хәрәкәт итү өчен ышанычлы нигез булдыруда шактый көч куясы бар әле...

Әлбәттә, табигать һәм байтак кына тышкы факторлар йогынтысы булды. Ләкин иң мөһиме

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



җитештерүне үстерүнең объектив шартларындагы үзгәрешләр үз вакытында тиешенчә бәяләнмәвендә, аны интенсивлаштыруны тизләтүдә, хуҗалык итү ысулларындагы үзгәрешләр зарурлыгы, дип уйлыйм һәм, бу бигрәк тә мөһим, икътисад өлкәсендә зур чаралар эшләүдә һәм аларны тормышка ашыруда тырышлык куелмады. Иптәшләр, безгә килеп туган вәзгыятьне тирәнтен һәм ахыргача аңларга һәм иң җитди нәтиҗәләр ясарга кирәк. Илнең тарихи язмышы, социализмның хәзерге дөньяда тоткан урыны күпчелек очракта безнең эшне киләчәктә ничек алып баруыбызга бәйле <...>

Төп мәсьәлә илебезнең икътисадый үсешкә ничек һәм нәрсә исәбенә ирешә алуына кайтып кала.. <...>»

**31** Доклад авторын һәм әлеге сәяси эшлекле ил белән җитәкчелек иткән чорны күрсәтегез.

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** *(җавапның, аның мәгънәсен бозмаучы башка формулировкалары да рөхсәт ителә)* | **Баллар** |
|---|---|
| Җавапта түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:<br>1) доклад авторы – М.С. Горбачёв;<br>2) чор атамасы – “үзгәртеп кору” | |
| Доклад авторы һәм чор дөрес күрсәтелгән | 2 |
| Бары тик доклад авторы гына дөрес | 1 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | |
|---|---|
| күрсәтелгән<br>ЯИСӘ бары тик чор гына дөрес күрсәтелгән | |
| Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

**32** Өзекнең беренче абзацыннан сәбәпләре икенче абзацта күрсәтелгән вакыйга тасвирланган җөмләне табыгыз һәм языгыз. Әлеге вакыйганың ким дигәндә ике сәбәбен күчереп языгыз.

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр**<br>*(җавапның, аның мәгънәсен бозмаучы башка формулировкалары да рөхсәт ителә)* | **Баллар** |
|---|---|
| Җавапта түбәндәге җөмлә күрсәтелергә тиеш:<br>«Мәгълүм ки, соңгы елларда уңайсыз тенденцияләр көчәйде, байтак кыенлыклар килеп чыкты».<br>Түбәндәге сәбәпләр күрсәтелергә мөмкин:<br>1) табигать һәм байтак кына тышкы факторлар йогынтысы;<br>2) җитештерүне үстерүнең объектив шартларындагы үзгәрешләр үз вакытында тиешенчә бәяләнмәвендә, аны | |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



| | |
|---|---|
| интенсивлаштыруны тизләтүдә, хуҗалык итү ысулларындагы үзгәрешләр зарурлыгы;<br>3) икътисад өлкәсендә зур чаралар эшләүдә һәм аларны тормышка ашыруда тырышлык куелмады | |
| Җөмлә (яисә башка формулировкада аның мәгънәсе дөрес бирелгән) һәм ике сәбәп дөрес күрсәтелгән | 2 |
| Җөмлә (яисә башка формулировкада аның мәгънәсе дөрес бирелгән) һәм бер сәбәп дөрес күрсәтелгән | 1 |
| Җөмлә генә (яисә башка формулировкада аның мәгънәсе дөрес бирелгән) дөрес күрсәтелгән<br>ЯИСӘ бары тик сәбәпләр генә дөрес күрсәтелгән (теләсә күпме)<br>ЯИСӘ җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

**33** Язгы чәчү алдыннан крестьяннар, җирле һәм үзәк хакимиятнең көчсезләнүеннән файдаланып, җирле алпавытларның җирләрен һәм мөлкәтен бүлә башлады. Ә көзен крестьяннарга алпавыт җирләрен законлы рәвештә бүлә алу хокукы теркәлгән Советлар съезды декреты бастырып чыгарылды.

1. Әлеге вакыйгалар булырга мөмкин булган елны күрсәтегез.
2. Ни өчен җирле һәм үзәк хакимият көчсезләнде һәм аннан крестьяннар файдалана алды?
3. Аның нигезендә алпавыт җирләрен бүлү законлаштырылган документ ничек атала?

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** *(җавапның, аның мәгънәсен бозмаучы башка формулировкалары да рөхсәт ителә)* | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавапта түбәндәге <u>элементлар</u> күрсәтелергә тиеш:<br>1) әлеге вакыйгалар булган ел – 1917 ел;<br>2) сәбәбе, мисал өчен: монархия бетерелгәннән соң Советлар һәм Вакытлы хөкүмәт арасында | |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



| | |
|---|---|
| каршылыклар туа, алар хакимиятнең көчсезләнүенә китерә;<br>(башка дөрес булган сәбәп күрсәтелергә мөмкин)<br>3) документ – Җир турында декрет | |
| Җавапта өч элемент дөрес күрсәтелгән | 3 |
| Җавапта теләсә кайсы ике элемент дөрес күрсәтелгән | 2 |
| Җавапта теләсә кайсы бер элемент дөрес күрсәтелгән | 1 |
| Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *3* |

**34** Шундый фикер яшәп килә: таркалганлык чорында, сәяси мөстәкыйль кенәзлекләр корылышында аерымлыклар булуга да карамастан, рус җирләре үсешендә бик күп охшашлыклар булды. Әлеге охшашлыкларны раслаучы кимендә ике факт китерегез.

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** *(җавапның, аның мәгънәсен бозмаучы башка формулировкалары да рөхсәт ителә)* | **Баллар** |
|---|---|

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | |
|---|---|
| Түбәндәге <u>фактлар</u> күрсәтелергә мөмкин:<br>1) барлык рус кенәзлекләрендә яшәүчеләр бер телдә сөйләшкән;<br>2) барлык рус кенәзлекләрендә яшәүчеләр бердәм борынгы рус халыклары булып тора;<br>3) барлык рус кенәзлекләрендә яшәүчеләр христиан (православие) динен тоткан;<br>4) барлык рус кенәзлекләрендә яшәүчеләр Русская правда законнар җыелмасыннан башланган бердәм хокукый нормалар нигезендә яши<br>Башка фактлар да китерелергә мөмкин | |
| Ике факт дөрес күрсәтелгән | 2 |
| Бер факт дөрес күрсәтелгән | 1 |
| Бирем таләпләренә туры килмәүче гомуми характердагы фикерләр китерелгән<br>ЯИСӘ җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

**35** Сезгә “Бөек Ватан сугышы барышында тамырдан борылыш” темасы буенча киңәйтелгән җавап әзерләргә кушылган. Әлеге теманы яктырту өчен нигез булып торачак план төзегез.

План кимендә өч пункттан торырга тиеш. Теләсә-кайсы ике пунктның кыскача эчтәлеген языгыз.

Аңлатмалы план Бөек Ватан сугышы барышында тамырдан үзгәрешләр белән бәйле төп вакыйгаларны (күренешләрне) чагылдырырга тиеш.





*Әлеге теманы тулысынча ачарга ярдәм итүче план төзергә кыенсынсагыз, теманың бер мөһим соравын (кисәк, юнәлеш, мәсьәлә) сайлап ала аласыз.*
*Үзегез сайлап алган сорау буенча планның исемен языгыз (кисәк, юнәлеш, мәсьәлә) һәм аның эчтәлеген ачып бирүче план төзегез. План төзегәндә пунктлар һәм аңлатмалар санына таләпләрне үтәгез.*

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр**<br>*(җавапның, аның мәгънәсен бозмаучы башка формулировкалары да рөхсәт ителә)* | **Баллар** |
|---|---|
| Җавапны анализлаганда түбәндәгеләр исәпкә алына:<br>- планның һәм аның аңлатмаларының | |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | |
|---|---|
| ничә пункттан торуы;<br>- план пунктлары формулировкаларының бирелгән темага туры килү-килмәве;<br>- план пунктларына аңлатмаларның дөрес булуы (бирелгән мәгълүматның тулылыгы һәм фактик хаталарның булмавы) | |
| *Темадагы биремнең аерым соравы буенча план (кисәк, юнәлеш, мәсьәлә) тема буенча барлык җаваплар планына карата критерийлар буенча бәяләнә. Эксперт өчен имтихан бирүче тарафыннан күрсәтелгән план (сорау, кисәк, юнәлеш, мәсьәлә) исеме ориентир булып тора. Әгәр дә чыгарылыш укучысы үзенең планына исем бирмәгән (сорау, кисәк, юнәлеш, мәсьәләне күрсәтмәгән) очракта, эксперт эшне биремдә бирелгән тема буенча план буларак тикшерә.* | |
| Әлеге теманы ачып бирү өчен план вариантларының берсе<br>1. Бөек Ватан сугышы барышында тамырдан борылыш төшенчәсе.<br>2. Тамырдан борылышның беренче этабы (1942 елның ноябре – 1943 елның язы): | |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



| | |
|---|---|
| а) Совет гаскәрләренең Сталинград янында контрһөҗүме;<br>б) Төньяк Кавказда, Урта һәм Югары Донда, Брянск һәм Курск юнәлешләрендә уңышлы операцияләр;<br>в) сәнәгатьне хәрби җайга салуны тәмамлау;<br>г) партизаннар хәрәкәтенең үсүе.<br>3. Тамырдан үзгәрешнең икенче этабы (1943 елның җәе – 1943 елның ахыры).<br>Икенче этапка Курск сугышы, Днепр өчен сугыш, СССРда хәрби производствоның иң югары дәрәҗәгә күтәрелүе, Гитлерга каршы коалициянең ныгуы (Тәһран конференциясе).<br>4. Бөек Ватан сугышы барышында тамырдан борылыш нәтиҗәсе.<br>План пунктларының саны башка төрле һәм (яисә) бүтән корректлы формулировкалары булырга мөмкин. Алар исем бирү, сорау формасында яисә катнаш формада була ала.<br>Аңлатмалар пунктчалар (п.2), позицияләрнең номер куелмаган исемлеге (п.3), ирекле формада комментарияләр рәвешендә бирелергә мөмкин. | |
| План кимендә өч пункттан торырга тиеш, аларның икесенә аңлатма бирелә. | 3 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | |
|---|---|
| План пунктлары һәм аларга аңлатмалар теманың (сайлап алынган сорауның) эчтәлеген чагылдырырга тиеш; аңлатмада фактик хаталардан тыш, план пунктларының эчтәлеген бирүче төп тарихи вакыйгалар китерелә. | |
| План кимендә өч пункттан торырга тиеш, аларның берсенә аңлатма бирелә.<br>План пунктлары һәм аларга аңлатмалар теманың (сайлап алынган сорауның) эчтәлеген чагылдырырга тиеш; фактта хаталары булмаган аңлатмада, план пунктларының эчтәлеген ачучы төп тарихи вакыйгалар китерелә.<br>ЯИСӘ<br>План ике пункттан тора, аларның икесенә дә аңлатма бирелә.<br>План пунктлары һәм аларга аңлатмалар теманың (сайлап алынган сорауның) эчтәлеген чагылдырырга тиеш; фактик хаталарсыз аңлатмада , план пунктларының эчтәлеген бирүче төп тарихи вакыйгалар китерелә.<br>ЯИСӘ<br>План кимендә өч пункттан торырга тиеш, | 2 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



| | |
|---|---|
| аларның икесенә аңлатма бирелә.<br>План пунктлары теманың (сайлап алынган сорауның) эчтәлеген чагылдыра.<br>Планның бер яисә ике пунктына аңлатмаларда, дөрес позицияләр белән бергә, җавапка аеруча зур хилафлык китермәүче фактик хата(лар) булырга мөмкин; ЯИСӘ планның бер яисә ике пунктына аңлатмаларда, дөрес, ләкин план пунктларын тулысынча ачып бирмәүче төп түгел, ә аерым фактлар гына китерелгән. | |
| План аңлатмаларсыз кимендә өч пункттан тора, ЯИСӘ аңламалар рәвешендә тема буенча конкрет мәгълүмат бирмәүче гомуми фикерләр китерелә.<br>План пунктлары формулировкалары теманың (сайлап алынган сорауның) эчтәлеген чагылдыра һәм аларда фактик хаталар булмый.<br>ЯИСӘ<br>План ике пункттан тора, аларның берсенә аңлатма бирелә.<br>План пунктлары һәм аларга аңлатмалар теманың (сайлап алынган сорауның) эчтәлеген чагылдырырга тиеш; аңлатмада | 1 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | |
|---|---|
| фактик хаталарсыз, план пунктларының эчтәлеген бирүче төп тарихи вакыйгалар китерелә.<br>ЯИСӘ<br>План кимендә өч пункттан торырга тиеш, аларның берсенә аңлатма бирелә.<br>План пунктлары формулировкалары теманың (сайлап алынган сорауның) эчтәлеген чагылдыра.<br>План пунктына аңлатмада, дөрес позицияләр белән бергә, җавапка аеруча зур хилафлык китермәүче фактик хата(лар) булырга мөмкин; ЯИСӘ план пунктына аңлатмада, дөрес, ләкин план пунктларын тулысынча ачып бирмәүче төп түгел, ә аерым фактлар китерелгән.<br>ЯИСӘ<br>План ике пункттан тора, аларның бер-ике пунктына аңлатма бирелә. План пунктлары һәм аларга аңлатмалар теманың (сайлап алынган сорауның) эчтәлеген чагылдыра. Планның бер яисә ике пунктына аңлатмаларда, дөрес позицияләр белән бергә, җавапка аеруча зур хилафлык китермәүче фактик хата(лар) булырга мөмкин. | |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



| | |
|---|---|
| ЯИСӘ<br>План пунктлары гомуми характерда була һәм алар теманың (сайлап алынган сорауның) эчтәлеген чагылдырмый, ләкин планның бер яисә ике пунктына аңлатмаларда фактик хаталар булмый һәм алар теманың (сайлап алынган сорауның) кайбер аспектларын ача. | |
| План аңлатмаларсыз ике пункттан тора, ЯИСӘ аңлатмалар рәвешендә тема буенча конкрет мәгълүмат бирмәүче гомуми фикерләр китерелә.<br>ЯИСӘ<br>План, аңлатмаларның сыйфатына бәйсез рәвештә, ике пункттан ким була.<br>ЯИСӘ<br>План пунктлары теманың (сайлап алынган сорауның) эчтәлеген чагылдырмый. Планның бер пунктына аңлатмаларда фактик хаталар булмый һәм алар теманың кайбер аспектларын ача.<br>ЯИСӘ<br>План пунктларында һәм аларга аңлатмаларда теманың (сайлап алынган сорауның) эчтәлеген бозучы һәм чыгарылыш | 0 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | |
|---|---|
| укучысының теманы аңламавын раслаучы фактик хата(лар) бар.<br>ЯИСӘ<br>План биремдәге теманың төп өлеше булып тормаучы сорауны (кисәк, юнәлеш, мәсьәлә) чагылдыра. | |
| *Максималь балл* | *3* |

Төп гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациялəве үткәрү тәртибе (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 25 декабрендәге 1394 номерлы боерыгы Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2014 елның 3 февралендәге 31206 номерлы карары белән теркәлгән) нигезендә

«48. Имтихан эшләре ике эксперт тарафыннан тикшерелә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча экспертлар бер-берсеннән бәйсез рәвештә имтихан эшләре биремнәренә җавапларның һәркайсына баллар куя... Ике эксперт куйган баллар арасында җитди аерма булган очракта өченче тикшерү билгеләнә. Балларда җитди аерма тиешле уку предметы буенча бәяләү критерийларында билгеләнгән.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



Өченче эксперт предмет комиссиясе рәисе тарафыннан имтихан эшен элек тикшермәгән экспертлар арасыннан билгеләнә.

Өченче экспертка укучының имтихан эшен элек тикшергән экспертлар куйган баллар турында мәгълүмат бирелә. Өченче эксперт куйган баллар ахыргысы булып тора».

Биремнәрнең теләсә кайсын үтәгән өчен баллар аермасы 2 һәм аннан күбрәк булса, *өченче эксперт шундый җитди аермага китергән биремнәрне генә тикшерә.*

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте